**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2014 елның 4 феврале № К-12/03-03

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәүләре дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, билгеләп куйганда конкурс игълан ителмәскә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе вазыйфаи затларын һәм гражданнарын дәүләт серен кулланууга кертү тәртибе турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 6 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган күрсәтмә нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәүләре дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, билгеләп куйганда конкурс игълан ителмәскә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының кушымта итеп бирелүче исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Аверьянова Э.М.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга тиеш.

3. “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәүләре дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, билгеләп куйганда конкурс игълан ителмәскә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 08.04.201 № К-29/03-03 боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Министр Л.Ю. Глухова

Татарстан Республикасы
Юстиция
министрлыгының
2014 елның 4
февралендәге
№ К-12/03-03 борыгына
кушымта

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
вазыйфаи бурычларны үтәүләре дәүләт серен тәшкил
итүче белешмәләрне файдалануга бәйле, билгеләп
куйганда конкурс игълан ителмәскә мөмкин булган дәүләт
граждан хезмәте вазыйфалары
ИСЕМЛЕГЕ

1. Министрның беренче урынбасары
2. Министр урынбасары
3. Эшләр буенча идарәче
4. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы
5. Финанс бүлеге башлыгы
6. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы урынбасары
7. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалар бүлегенең әйдәүче белгече